DOI: 10.26907/2311-2042-2022-19-2-55-65

# MUHAMMED IDRISOV'S STORIES: IDEOLOGICAL-AESTHETIC AND GENRE FEATURES

**Nuria Midkhatovna Miftahutdinova,**
National Museum of the Republic of Tatarstan,
2 Kremlevskaya Str., Kazan, 420011, Russian Federation.
nurija08@yandex.ru

The article examines the literary activity of M. Idrisov, an outstanding printer, font master and the author of textbooks. The study is based on the stories of this multi-talented cultural figure. "No Wings to Fly" and "A Lucky Ticket" were published in 1916 in the journal "Аң" ("Consciousness") and became the object of our scientific evaluation. The subject of the study is their ideological and aesthetic originality.

The stories reveal the features of artistic thinking, characteristic of the literature in the early 20th century, intercultural ties, the role of musical images, the parallelism of natural phenomena and the human world in conveying the emotions of the characters. M. Idrisov's story "A Lucky Ticket" is an attempt to write a work in the field of humor and satire.

**Key words**: Tatar literature, Muhammed Idrisov, story, genre, literary relations, social thought, culture

## Introduction

The samples of Tatar literature of the early 20th century have survived to this day owing to the pages of periodicals. Most of the authors of these works remain unknown to the modern reader, since among them there were those who chose professions that were not related to literary and creative activities. Those works mark the period of searching for oneself in different fields. Despite of their amateurish character, those stories were distinguished by their ideological and problematic relevance and, generally, they reflected ideological and aesthetic features of the early 20th century literature.

A number of works that appeared on the pages of the periodical press were published under secret pseudonyms, as it was customary in those days. In his work devoted to establishing the authorship of literary texts, the literary critic and textologist Z. Ramiev identifies literary pseudonyms and indicates the presence of about seventy known and unknown G. Tukay's and twenty F. Amirkhan's pen names [1, p.18]. It is also known that Zakir Ramiev, the owner of gold mines, a sponsor and a talented poet, also used a pseudonym.

## Materials and methods

This scientific research is based on the stories "No Wings to Fly" and "A Lucky Ticket", published in 1916 in the journal "Аң" under the pseudonym I. Muhammad [2], [3]. The purpose and the object of our study determined the methods and principles of the analysis. We used the cultural-historical, comparative-historical and biographical methods for analyzing the literary works.

## Discussion

The identity of the author of these stories, published under the pseudonym I. Mukhammed in Issues 22 and 23 of the journal "Аң" ("Consciousness") in 1916, was established as a result of chance and was corroborated in the course of serious research.

To mark the 85th anniversary of M. Idrisov, a famous printer, cartographer, graphic artist and a type master, his wife Rabiga Idrisova, his sister M. Idrisova Galia and her husband Mikhail Pichakhchi, an engineer-scientist, did a lot to return the valuable scientific works of the inventor to the people. The source of information about M. Idrisov's biography and scientific activities are the memoirs, research and M. Pichakhchi's correspondence with various organizations [4]. At present, his handwritten work is stored in the National Museum Fund, while the copies and originals of some materials, related to M. Idrisov, are in the scientific library of Kazan Federal University named after N. I. Lobachevsky. M. Pichakhchi called his work "History with Geography Relating to the History of the Kazan Self-Made Printer Muhammad Ibragimovich Idrisov". In the process of reading, you can understand the reason why the concept of geography appeared in the title of the work. M. Pichakhchi negotiated the transfer of the

archive in Moscow, Kazan, Ufa, and even in a sanatorium, where he was recovering from a heart attack.

The result of this activity was the article "Our Outstanding Printer" by S. Z. Latypov, the Chief Engineer of the Printing Department at the Council of Ministers of the Bashkir Autonomous Soviet Socialist Republic, published in the journal "Agidel" [5] and a program on Ufa television, dedicated to the activities of M. Idrisov.

It should be noted that after the death of her husband in 1948, R. Idrisova handed over part of his archive, his handwritten works, to F. Tagirov, who had worked under M. Idrisov's direction in the same institute. In the 1960s, she donated some of the materials that were in her keeping to M. Pichakhchi, as well as to research institutes, archives and libraries. Trying to promote his legacy, she repeatedly turned to the editors of newspapers and magazines raising the issue of publishing an article about M. Idrisov. Based on her materials, in 1966, the articles were published in the newspapers "The Socialisticheskiy Tatarstan" in Kazan [6] and "The Sovetskaya Bashkiria" in Ufa [7].

To popularize the legacy of the outstanding personality and introduce it into active scientific circulation, M. Pichakhchi met with people who knew Muhammad Idrisov personally. Among them were F. Tagirov, who had worked at Niipoligraphmash under M. Idrisov's direction, A. G. Shaikhgali (1885—1968), who had retired from the post of director of the first typewriter plant in Kazan, Zainab Khasani (1885—1967), the wife of the "An" magazine editor Akhmet Garey Hasani (1883—1933) with whom M. Idrisov and other famous people collaborated. Unfortunately, due to M. Pichakhchi's illness and his unsuccessful attempts to meet some of these people, many memories remained unrecorded. During these years, M. Idrisov's friend Shigab Akhmerov (1882—1966) passed away.

In the course of their meeting, Zaynab Khasani told M. Pichakhchi that in the issue of the magazine "An" (1916), stored in the family archive, there were M. Idrisov's stories "No Wings to Fly" and "A Lucky Ticket", published under the pseudonym I. Muhammed [4, p. 6]. She retold their content to M. Pichakhchi in Russian.

The talented journalist Zainab Hasani got an excellent education, together with her husband, Ahmetgarey Hasani, they published the magazine "An" (1912—1918). M. Idrisov collaborated with such magazines as "An" ("Consciousness"), "Yashen" ("Lightning"), "Karchyga" ("A Hawk"), "Fiker" ("A Thought"). G. Tukay, G. Ibragimov, F. Amirkhan and other writers were his circle of contacts. The magazine "An" was published in Kazan in Kharitonov's printing house and the "Millat" ("Nation") [8, p. 50]. It was a "literary, scientific, political and public illustrated magazine", which differed from the publications of that time not only in its technical characteristics, but also in the philosophical and semantic depth of the published material content, the relevance of the issues raised, the richness of descriptions and the novelty of its pictorial design, it united the circle of the most talented writers.

M. Idrisov is also known to be an author. Before the revolution, he annually published new textbooks on mathematics and geography, which had explanations of Arabic-Persian terms in the Tatar language understandable to Tatar children. We can get acquainted with the bibliography of his works in the archival list written by the author himself [9], as well as in the bibliography compiled by R. Mardanov and I. Khadiev [10].

As is known, in the 1910s, the works of K. Tinchurin, Sh. Akhmadiev, G. Gaziz, G. Rakhim, S. Jalil, G. Rafiki, M. Gali, N. Gasriy, Hanafi, S. Rakhmankoly and others enriched Tatar prose. The work of young writers, with different degrees of knowledge and talent, was distinguished by ideological and thematic diversity, genre richness, artistic techniques and methods. [11, p. 162]. M. Idrisov also made his contribution to the formation of the New Age prose. The stories, mentioned above, were written by him during the years of his work as the head of the printing house "Millat" ("Nation") (1915—1917). Along with experiments in the printing, he tries himself in the field of literary work.

In the story "No Wings to Fly", distinguished by its psychological insight, the events take place during the First World War. The disaster, brought by the war, is described based on the fate one young family. A number of research works on the reception of war in the early twentieth century prose are written by literary critics and historians [12], [13], [14], [15]. However, until now, this story of the famous printer has not drawn attention of literary critics. We dare to remind you that in Tatar literature there are not many works, in which the whole burden of the First World War and the degree of grief felt by the common people is revealed through the tragic fate of a woman.

In the literature of the early 20$^{th}$ century, one of the most important topics was the depiction of people's behavior in harsh circumstances, in ex-

ceptionally tense moments. Tatar writers relied on the experience of Russian writers, on their discoveries in the field of in-depth psychological analysis and their mastery of cultural relationships. In M. Idrisov's story "No Wings to Fly", the inner feelings of the main character are revealed by using the method of hidden psychologism, characteristic of I. S. Turgenev's work. The Russian writer created the theory of "secret psychology", according to which "the psychologist must disappear in the artist, as a skeleton disappears from our eyes under a living and warm body to which it serves as a strong but invisible support". "The poet must be a psychologist, but a secret one: he must know and feel the roots of the phenomena, but represent only the phenomena themselves - in their heyday or withering".

It is with great skill that M. Idrisov managed to reveal the inner intimate feelings of his literary heroine, using various techniques, on the verge of the imaginary and the real. Reflecting on the fate of the woman, the writer associates the cause of Nasima's misfortune with the war. The newlyweds, Gabdrakhman and Nasima, managed to live happily for a few months only. Soon the husband went to war, and the wife received the news of his death. The woman's suffering, which escalated after Gabdrakhman's departure to the front, was exacerbated by her difficult relationships with her mother-in-law, Makhubzhamal Abystai. In the story, Nasima's psychological drama is presented in a close relationship with social conditions. Thematically, the work echoes M. Gafuri's story "Hamida, a Soldier's Wife", which realistically and authentically describes the complicated psychological experiences of Hamida, whose husband went missing in the war [16, pp. 294–295].

In "No Wings to Fly" the events take place in the city of Ufa. It begins with a description of a widowed woman who walks in the garden all alone, feeling weak and sad, and looks at the Belaya River. This is the moment when the writer tries to convey to the reader Nasima's suffering from being lonely, her wave of emotions caused by her helplessness. In the scenes where the author depicts Nasima's painful experiences, we can feel the influence of the philosophy of existentialism. The state of loneliness is conveyed through the description of her emotions, at the same time, the events associated with these emotions show the development of Nasima's level of self-consciousness.

The Tatar writer chooses a "speaking name" for his main character in order to precisely characterize her dreamy nature. G. Sattar-Mulille explains the semantics of this female name in this way: "yomshak kүnelle, molai" ("pretty, sensitive") [17, p. 402]. The name of her beloved one means "mөrkhəmattlenenң, rakhimlenenң (Allahynyң) cola" ("the slave of all-merciful Allah") [17, p. 79]. If M. Idrisov portrays the image of a girl through the element of love, the image of a man is given through the motif of submission to fate.

To reveal the inner world of a woman, the writer skillfully uses the potential of portrait characteristics based on the principle of contrast. M. Idrisov compares the portrait of the widow with Nasima's portrait in her girlhood: "Her tall and round body of a girl has lost weight, melted; once ruddy cheeks have turned pale and fell off like flowers. Her eyes, playful and charming in her youth, have grown dim and are filled with fatigue, blue bags have appeared under her eyes, her gaze is turned inward.

Following the traditions of romantic prose, M. Idrisov, depicts the feelings of his main character in close connection with descriptions of nature. Nasimi's sufferings are compared with spring floods on the Volga River, and the surrounding reality is compared with a stream. "It seemed to her that the Volga was overflowing with tears of women as unfortunate as she was. The waters of the river were mixed with the burning tears of many daughters-in-law, living in families along the banks of the river and beyond the mountains, women separated from their husbands, girls forcibly married ..." [2]. Immersed in deep emotional experiences, the woman remembers the times when she walked in this garden a year ago with her husband Gabrakhman. Those moments are the happiest in Nasima's heart.

The suffering of the widow becomes unbearable because of the jealousy that the mother-in-law has always felt for her daughter-in-law. Nasima cannot forget the angry words of Gabdrakhman's mother who said as a goodbye to her: "You have bewitched my son, subjugated him". She does not feel guilty towards her mother-in-law, because all her fault was her sincere love and devotion to her husband: "She fell in love with Gabdrakhman at first sight, when she was a young girl, and he was in love with her. Even after their first acquaintance, it was pleasant for Nasima with her passionate heart, to remember Gabdrakhman, who was distinguished by his heroic appearance, who was a handsome man with a finely defined black mustache" [2].

The insults that her mother-in-law was peppering on her and their quarrels made Nasima leave her husband's house. The writer points out all the injustice of these reproaches, as well as the depth of the young woman's suffering because of them: "These words plunged into the wounded heart of Nasima Khanum with a poisonous arrow" < > "Did I bewitch him, did I plot against his parents? I just loved him! And he had the same feelings... He loved me".

The Tatar folk song "Lemonade", which a group of soldiers is singing in the garden, increases the degree of emotions in Nasima's heart. For a moment it seems to her that her Gabrakhman is among them, her beloved husband is about to appear before her. Due to the experiences that have flooded over her, the girl falls into a state of ecstasy, finding herself on the verge of visions and reality.

"Here, she seems to be flying ...

Nasima khanum is greeted by the soldiers:

- You have wings to fly! they exclaim. Here, she seems to be rising higher and higher ..." [2].

Following the canons of romantic aesthetics and I. Turgenev, M. Idrisov considered music and images of nature to be the best way to reveal the inner world of his characters. Therefore, both the sounds of nature and the folk song perform an important ideological and aesthetic function in the story. This wedding song reflects the feelings of lovers and the pain of separation. At the same time, the song contains a philosophical idea that happiness awaits young people in the future.

The clash of dreams and reality is given in the story through the antithesis "I have no wings to fly", a line from the song, and the same line paraphrased by the soldiers: "You have wings to fly". Nasima dreams she were flying. It is clear that her husband was her wings. The arrival of Garif, a relative, who has come to take Nasima away with him, actually means the onset of a new stage in her life. Happy, joyful days, spent with Gabdurakhman, are left far behind, only the wings of a dream can bring them back again.

Not a word about Nasima's new life is said in the story, but the friendly embrace of her relative, who thus demonstrates his spiritual support, gives her confidence in a happy future. Nasima, through the memories of the happy moments with Gabdrakhman, says goodbye to her husband forever.

In the 1910s, the genre of the story became more activate in Tatar prose in its various manifestations: psychological, journalistic, historical, satirical, humorous stories, short stories, etc. M. Idrisov's story "A Lucky Ticket" was created at the intersection of humor and satire. The story about Faskhetdin Gainetdinovich, who lives in the city, and about the events that happened to him, congenially resembles the satirical and humorous works of F. Amirkhan, Sh. Kamal and G. Gubaidullin.

The plot is based on the story of the lottery draw in the famous Kazan Swiss Park. The rumor about the lottery has spread throughout the city. Among the things in the lottery were a bicycle, a silver watch, a gramophone, a live cow, first-class flour from Okoloshnikov, refined sugar and firewood.

The "artisan" Fashhetdin of the lame-footed Ahmadi, or the bay's master named Ahmadi, wins a live cow with a lottery ticket bought in the park. M. Idrisov describes this event with deep irony: "If it isn't happiness! A happy ticket!"

He quarrels with his mistress Sharifa, who does not want to walk around the city with a cow on a leash; therefore, with great difficulty, he arrives at the house where he lodges, all alone. When he returns, he does not know where to put the cow up for the night? Fashhetdin does not have his own house. He rents a room from a rich man. His neighbor, Minibay Abzy, began to shower him with advice, which contained mockery. On hearing the cow low, the owner comes out of the house and, getting angry, drives Faskhutdin with the cow out of the house. After walking for a long time, the poor fellow falls asleep on the ground, "near the oil tanks located between two villages". At night the cow has been stolen.

He tries to find the loss by contacting the police station, but he is denied help, because he does not remember the details of the stolen animal. Yesterday, he was rich, because he had a cow, a mistress, and a place where he could rest after work. Today he is left with nothing. The lucky ticket has led to serious consequences in his life [3].

The writer endows his hero with an expressive appearance: "The origins of the tragedy are in his head, he is dimwitted, like a cow. Among his comrades, he is known be stupid and dumb. Itelligence is not his strong point. The people around him always make fun, scoffle and mock at him". [3]

Of interest is M. Idrisov's literary style. The writer uses the potential of artistic means borrowed from folklore. Distinctive features of his style are the use of proverbs and sayings, winged words, nicknames, etc. To hook the reader, the writer, at the beginning of the story, resorts to sincere into-

nation asking the question “can I buy a ticket to happiness or not?” In this way the writer creates intrigue, adding mystery and stimulates the reader’s interest, prepares him for reading.

## Results

The works “No Wings to Fly” and “A Lucky Ticket” by M. Idrisov are written in the style of realism. They describe the sufferings, born in the soul of the main character affected by the harsh reality of the era. However, the two stories differ from each other in their style. In the first one, the author depicts the inner world of Nasimi according to the canons of romantic aesthetics, in this way protesting against the war, in the second story, human nature is criticized through the creation of a comical character and a number of comic situations. Subtle humor, reaching open sarcasm, conciseness - all this is the individual features of M. Idrisov’s satirical work. In general, the literary critic D. Zagidullina defines the features of the story, written at the beginning of the 20th century, in the following way: “the beginning of the 20th century is rightly regarded as the period of the Tatar story formation, the search for new ways of transforming literature, as the period when the genre reaches the highest point in its development” [18, p. 3].

## Conclusions

Tatar literature of the early 20th century has gone down in history as the era of the Renaissance. The works of G. Tukay, F. Amirkhan, N. Dumavi, S. Sunchaley, S. Ramiev, Derdemend and other writers constitute the golden fund of Tatar literature. If M. Idrisov had connected his fate with writing, he would have taken his rightful place in literature next to these outstanding writers.

**References**

1. Rəmiev, Z. Z. (2000). *XXiөz bashy tatar ədəbiyaty: avtorlyk, tөp tekst həm khronologiya məs'ələləre* [Tatar Literature of the Beginning of the 20th Century: Issues of Authorship, Main Text and Chronology]. 180p. Kazan, RITS “Shkola”. (In Tatar)

2. Mөkhəmmət, M. (1916). *Yuk kanatym ocharga* [No Wings to Fly]. Аң. No. 21, pp. 326–328. (In Tatar)

3. Mөkhəmmət, M. (1916). *Bəkhet bilety* [A Lucky Ticket]. Аң. No. 22, pp. 343–346; No. 23, pp. 362–365. (In Tatar)

4. NM RT KPPi 124639. Pichakhchi, M. (1967). *Istoriya s geografiei, otnosyashchiesya k istorii Kazanskogo poligrafista-samorodka Mukhammeda Ibragimovicha Idrisova* [History with Geography Relating to the History of the Kazan Self-Made Printer Muhammad Ibragimovich Idrisov]. Kazan'. (In Russian)

5. Latipov, S. (1967). *Kүrenekle poligrafisebez* [Our Outstanding Printer]. Agizel. No. 5, pp. 93–95. (In Tatar)

6. Təkhfatullin, Z., Kushaev, G. (1966). *Ul beznең safta* [He Is in Our Ranks]. Sots. Tatarstan. 5 mai. (In Tatar)

7. Latypov, S. (1966). *Poligrafist-uchenyi* [The Printer-Scholar]. Sov. Bashkiriya. 28 avgusta. (In Russian)

8. Rəmiev, I. (1926). *Vakytly tatar matbugaty. 1905–1925* [Temporary Tatar Press]. 232 p. Kazan, Gazhur. (In Tatar)

9. NMRT KPPi 124639 *Trudy Idrisova M. I.* [M. Idrisov’s Works]. (In Russian)

10. Mərdanov, R., Һadiev, I. B. (2022). *“Millət matbagasy həm Mөkhəmmad Idrisi ehshchənlege”* [“The National Press and the Activities of Mohammad Idrisi”]. Mukhammed Idrisov – master shrifta. L. I. Galiev. S. V. Morozova, N. M. Miftakhutdinova, M. L. Akhmadullina, I. G. Khadiev, R. F. Mardamanova. Ufa, Vostochnaya pechat', pp. 91–93. (In Tatar)

11. Gyilaжev, T. (2005). *Shəhit Əkhmədiev: tormyshy həm iҗҫaty* [Shakhit Akhmadyev: His Life and Work]. T. Sh. Gyilaжev. Ədəbi miras: tarikh həm zaman. Pp. 161–171. Kazan, Tatar.kit nəshr. (In Tatar)

12. Gali, B. T. (2008). *Tatarskaya khudozhestvennaya literatura 1914–1917 godov kak istoricheskii istochnik* [Tatar Fiction of 1914–1917 as a Historical Source]. Uchen. zap. Kazan. un-ta. Ser. Gumanit. nauki. No. 8, pp. 183–188. (In Russian)

13. Gabdrafikova, L. R., Salikhov R. R. (2012). *Voennaya povsednevnost' v tatarskikh baitakh* [Everyday Life During the War in Tatar Bayts]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 4 (30), pp. 305 – 308. (In Russian)

14. Gilazov, T. Sh. (2015). *Liricheskii geroi poehzii M.Gafuri, posvyashchennoi teme voiny* [The Lyrical Hero of M. Gafuri’s Poetry Dedicated to the Topic of War]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 3 (41), pp. 208 – 213. (In Tatar)

15. Khabutdinov, A. Yu. (2015). *Tema Pervoi Mirovoi voiny v tatarskoi maloi proze nachala XX veka* [The Theme of the First World War in the Small Tatar Prose of the Early Twentieth Century]. Filologiya i kul'tura. Philology and Culture. No. 4 (42), pp. 255–259. (In Russian)

16. Gafuri, M. (1983). *Soldat khatyny Khəmidə* [Hamida, a Soldier's Wife]. Gafuri M. Əsərlər: dүrt tomda: 3 t.: Proza həm publitsistika (1902–1917). Pp. 267–295. Kazan, Tatar. kit.nəshr. (In Tatar)`

17. Sattar-Mulille, G. (1998). *Tatar isəmnəre ni səili?*[What Do Tatar Public Figures Say?]. 486 p. Kazan, Rannur. (In Tatar)

18. Zahidullina, D. (2001). *Tatar khikəyaləre: XX gasyr bashy* [Tatar Stories: The Beginning of the 20th Century]. 399 p. Kazan, Məgarif. (In Tatar)

# МӨХӘММӘТ ИДРИСОВ ХИКӘЯЛӘРЕНЕҢ ИДЕЯ – ЭСТЕТИК ҺӘМ ЖАНР ҮЗЕНЧӘЛЕГЕ

**Нурия Мидхат кызы Мифтахетдинова,**
Татарстан Республикасы Милли музее,
Россия, 420011, Казан ш., Кремль ур., 2 нче йорт,
nurija08@yandex.ru

Мәкаләдә күренекле полиграфист, шрифтлар остасы, дәреслекләр авторы М. Идрисовның әдәби эшчәнлеге тикшерелә. Күпкырлы талант иясенең «Юк очарга канатым», «Бәхет билеты» хикәяләре 1916 елда «Аң» журналында басылып чыга һәм алар фәнни хезмәтнең бәяләү объекты булып тора. Әдәби әсәрләрнең идея-эстетик үзенчәлекләре аның тикшерү предметын билгели.

Хикәяләрдә XX гасыр башы әдәбиятына хас сәнгатьчә фикерләү ысулы, мәдәниятара бәйләнешләр, геройларның хис-кичерешләре бирелешендә кеше белән музыка аһәңе, табигать күренешләрен кешелек дөньясы белән тәңгәлләштерү кебек үзенчәлекләр күренә. М. Идрисовның «Бәхет билеты» хикәясенең XX гасыр башы әдәбиятындагы сатира жанрын тулыландыручы әсәрләрнең берсе булуы ассызыклана.

**Төп төшенчәләр:** татар әдәбияты, Мөхәммәт Идрисов, хикәя, жанр, әдәби бәйләнешләр, иҗтимагый фикер, мәдәният

## Кереш

XX йөз башы татар әдәбияты үрнәкләре вакытлы матбугат битләре аша безнең көннәргә килеп җитте. Хәзерге укучыга мондый әсәрләрнең күпчелегенең авторлары билгесез булып кала бирә, чөнки алар арасында киләчәген язучылык, иҗат эшенә бәйләнеше булмаган һөнәрләр сайлаган шәхесләр дә бар. Бу хикәяләр автор өчен каләм тибрәтү тәҗрибәсе, яшьлектә үзеңне төрле өлкәдә сынап карау кебек бер мизгелне дә хәтерләтә. Шулай булуга да карамастан хикәяләр идея, проблемалары ягыннан актуаль, тулаем XX йөз башы әдәбиятының идея-эстетик үзенчәлекләрен гәүдәләндерә. Вакытлы матбугат битләрендә нәшер ителгән әсәрләрнең бер шәлкеме, ул чорларга хас булганча, яшерен тәхәллүсләр белән басылган. Әдәбият галиме, текстолог З. Рәмиев әдәби текстларның авторлыгын билгеләү, әдәби псевдонимнарны ачыклауга багышланган хезмәтендә Г. Тукайның җитмешләп, Ф. Әмирханның исә егермеләп ачык һәм яшерен имзалары булуын дәлилли [1, 18 б.]. Шулай ук алтын приискалар хуҗасы, иганәче, талантлы шагыйрь Закир Рәмиевнең тәхәллүсе Дәрдемәнд булуы билгеле.

## Тикшеренү материаллары һәм методлары

Фәнни тикшеренү материалы итеп 1916 елны «Аң» журналының 22 һәм 23 саннарында И. Мөхәммәт псевдонимы белән басылган «Юк канатым очарга», «Бәхет билеты» хикәяләре алынды [2], [3]. Тикшерү методлары һәм принциплары гыйльми эзләнү хезмәтенең максатына һәм өйрәнү объектына нигезләнеп сайланылды. Әдәби иҗатны, әсәрне шәрехләү һәм анализлауның культура-тарих, чагыштырма-тарихи, биографик методлары файдаланылды.

## Фикер алышу

И. Мөхәммәт псевдонимы белән 1916 елда «Аң» журналының 22 һәм 23 саннарында нәшер ителгән хикәяләр авторының кем булуы очраклы һәм шул ук вакытта тирән эзләнүләр нәтиҗәсендә билгеләнелде.

Танылган полиграфист, картограф, рәссам-график, шрифтлар остасы М. Идрисовның 85 еллык юбилее уңаеннан, хатыны Рабига Идрисова һәм М. Идрисовның сеңлесе Галия белән ире Михаил Пичахчи инженер - галим, уйлап табучының фәнни хезмәтләренең кыйммәтен халыкка кайтару юлында күп эш башкаралар. М. Пичахчиның истәлекләре, эзләнүләре, төрле оешмаларга язган хатлары М. Идрисовның фәнни эшчәнлеген, биографиясен ачыклауда төп чыганак булып торалар [4]. Хәзерге вакытта әлеге хезмәт Милли музей фондында, күчермәләр һәм М. Идрисовка кагылышлы кайбер материалларның оригинал нөсхәләре Казан федераль университетының Н. И. Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсендә саклана. М. Пичахчи үз

хезмәтен «История с географией, относящиеся к истории Казанского полиграфиста-самородка Мухаммеда Ибрагимовича Идрисова» дип атаган. География төшенчәсенең исемгә чыгарылу сәбәбен уку барышында аңлыйсың. Ул архивны тапшыру хакындагы сөйләшүләрне Мәскәү, Казан, Уфа шәһәрләрендә алып бара, хәтта инфарктан соң үзе булган санаторияләрдә дәваланучыларга М. Идрисовның эшчәнлеге турында сөйли.

Башкорт Автономияле Совет Социалистик Республикасы Министрлар Советы каршындагы матбугат идарәсенең баш инженеры С. З. Латиповның «Агыйдел» журналында басылган «Күренекле полирафиячебез» мәкаләсе [5] һәм Уфа телевидениесендә М. Идрисов эшчәнлегенә багышланган тапшыру әлеге эшчәнлекнең нәтиҗәсе булып тора.

Әйтергә кирәк, М. Идрисов вафатыннан соң (1948), Р. Идрисова аның беркадәр архивын, кулъязма хезмәтләрен ире белән бер институтта һәм турыдан-туры аның кул астында эшләгән Ф. Таһировка тапшыра. 1960 елларда Р. Идрисова үзендә сакланган материалларның бер өлешен М. Пичахчига бирә һәм шулай ук фәнни институтларга, архивларга, китапханәләргә дә тәкъдим итә. Бу юнәлештә актив хәрәкәт итеп, газета-журнал редакцияләре белән М. Идрисов турында мәкалә бастыру мәсьәләсен күтәрә. Аның материаллары нигезендә 1966 елда Казанда «Социалистик Татарстан» [6], Уфада «Советская Башкирия» [7] газеталарында мәкаләләр дөнья күрә.

М. Пичахчи тарафыннан күренекле шәхеснең исемен халыкка кайтару һәм аны таныту юнәлешендә башкарылган эшләр арасында Мөхәммәт Идрисовны күреп белгән шәхесләр белән очрашуы мөһим урын алып тора. Алар арасында М. Идрисов җитәкчелегендә НИИПолиграфмашта эшләгән Ф. Таһиров, Казанда беренче язу машиналары заводы директоры вазифасын башкарып лаеклы ялга чыккан Ә.Г. Шәйхгали (1885–1968), М. Идрисов хезмәттәшлек иткән «Аң» журналы редакторы Әхмәтгәрәй Хәсәнинең (1883–1933) хатыны Зәйнәп Хәсәни (1885–1967) һәм башка күренекле шәхесләр бар. Кызганыч ки, М. Пичахчиның авыруы һәм кайбер шәхесләрнең өйләрендә булмаулары сәбәпле, кайбер истәлекләр язылмый кала. Бу елларда М. Идрисовның дусты Шиһаб Әхмәров та (1882–1966) үлгән була.

Зәйнәп Хәсәни очрашу вакытында М. Пичахчига гаилә архивында сакланган «Аң» журналының 1916 елгы саннарында М. Идрисовның И. Мөхәммәт псевдонимы белән басылган «Юк канатым очарга», «Бәхет билеты» хикәяләре барлыгын әйтә [4, 6 б.]. Аларны укып, эчтәлеген М. Пичахчига рус телендә сөйли.

Зәйнәп Хәсәни үзе дә белемле һәм сәләтле журналист була, ире Әхмәтгәрәй Хәсәни чыгарган «Аң» (1912–1918) журналында эшли. М. Идрисов «Аң», «Яшен», «Карчыга» кебек журналлар белән хезмәттәшлек итә. Г. Тукай, Г. Ибраһимов, Ф Әмирхан һ.б. язучылар белән аралаша. «Аң» журналы Казанда «Милләт» һәм Харитонов типографияләрендә басыла [8, 50 б]. Үзенең техник характеристикалары белән генә түгел, ә басылган материаллар эчтәлегенең фәлсәфи һәм мәгънәви тирәнлеге, күтәрелгән проблемаларның актуальлеге, тасвирый алымнарның, сурәтләрнең байлыгы һәм яңалыгы белән ул вакытта нәшер ителгән журналлардан аерылып торган «әдәби, фәнни, сәяси вә иҗтимагый рәсемле журнал» «Аң» тирәсендә иң сәләтле язучылар туплана.

М. Идрисов китаплар авторы буларак та билгеле. Аның татар балаларына аңлаешлы, гарәп-фарсы терминнары татарча шәрехләп язылган математика, рәсемле география дәреслекләренең яңа басмалары 1917 елгы Октябрь революциясенә кадәр ел саен дөнья күрә. М. Идрисов хезмәтләренең библиографиясе хакында авторның үз кулъязмаларыннан [9], ә китаплары турында Р. Мәрданов һәм И. Һадиев хезмәтләреннән мәгълүмат алырга мөмкин [10].

Билгеле булганча, 1910 елларда татар прозасына иҗат мөмкинлекләре, сәләтләре һәм белем дәрәҗәләре төрле булган К. Тинчурин, Ш. Әхмәдиев, Г. Газиз, Г. Рәхим, С. Җәләл, Г. Рәфикый, М. Гали, Н. Гасрый, Хәнәфи, С. Рахманколый һәм башка яшь язучылар килә һәм алар иҗаты «жанр байлыгы белән генә түгел, идея-тематик киңлеге, иҗат принциплары, сурәтләү алымнарының төрлелеге белән дә аерылып тора» [11, 162 б.]. Әлбәттә, бу процесска М. Идрисов та мәгълүм өлеш кертә. «Юк канатым очарга», «Бәхет кошы» әсәрләренең язылу еллары М. Идрисовның «Милләт» типографиясендә мөдир булып эшләү вакытларына (1915–1917) туры килә. Димәк, типография эше белән бергә әле ул үзен язучы буларак та сынап карый.

«Юк канатым очарга» психологик хикәясендә вакыйгалар Беренче Бөтендөнья сугышы елларында бара. Сугыш алып килгән афәт бер яшь гаилә мисалында күрсәтелә. Бу тема гасыр башында дөнья күргән татар хикәяләре мисалында әдәбият белгечләре һәм тарихчылар тарафыннан шактый өйрәнелгән [12], [13], [14], [15]. Ләкин әлегә кадәр танылган полиграфистның бу хикәясе әдәбият галимнәре игътибарыннан читтә калган. Бу урында шуны да искәртеп китү урынлы булыр: татар әдәбиятында Беренче бөтендөнья сугышының гади халыкка алып килгән авырлыгын хатын-кыз фаҗигасе аша сурәтләгән әсәрләр күп түгел.

Әдәби әсәрдә гәүдәләндерелгән кырыс чынбарлыкта, киеренке, кискен мизгелләрдә кешеләрнең үз-үзләрен тотышларын сурәтләү - XX гасыр башы әдәбиятында мөһим бер темаларның берсе. Мәдәниятара бәйләнешләр, бигрәк тә көчле психологизм белән сугарылган рус язучыларының әсәрләре татар әдипләре өчен тәҗрибә мәктәбе була. М. Идрисовның «Юк канатым очарга» хикәясендә әдәби геройның тирән кичерешләре И. С. Тургенев иҗатында актив файдаланылган яшерен психологизм алымы ярдәмендә сурәтләнә. Мәгълүм булганча, күренекле рус язучысы әдәбият белемендә «яшерен психология» теориясе авторы буларак дан казана. И. С. Тургенев фикеренчә, язучы яшерен психолог булырга тиеш. Тән белән сокланганда, бер кеше дә скелетның әһәмияте турында уйламый. И. С. Тургенев язучы да күренешләрне тасвирлаганда, эчке процессларны дөрес аңлап, аларның ничек тууын, үсүен, юкка чыгуын яшерен, ачыктан-ачык күрсәтмичә ачарга тиеш дигән караштa тора.

М. Идрисов әдәби геройның эчке интим хис-кичерешләрен төрле тасвирлар, хыял һәм чынбарлык чикләре сурәтләнешендә иҗади осталык белән ачып бирә. Хатын-кыз язмышы турында уйланганда, язучы Нәсимә бәхетсезлегенең сәбәбен сугыш белән бәйли. Габдрахман белән Нәсимә, яңа гына гаилә корып, берничә ай гына бәхетле тормыш кичереп калалар. Ә аннары сугышка китү һәм иренең тетрәндергеч үлем хәбәрен алу сөйләнелә. Нәсимә белән кайнанасы Мәхүбҗамал абыстай арасындагы мөнәсәбәтләрнең киеренкелеге дә шушы вакыйгаларда тагын да кискенләшә һәм төп герой Габдрахман белән яшәгән йортны ташлап китәргә мәҗбүр була. Хикәядә Нәсимәнең психологик драмасы социаль шартлар белән бәйләнештә дә ачыла. Әсәрнең бу үзенчәлеге ире сугышка китеп хәбәрсез югалган Хәмидәнең авыр психологик кичерешләрен реалистик детальләрдә сурәтләгән М. Гафуриның «Солдат хатыны Хәмидә» хикәясе белән аваздаш [16, 294–295 б.],

«Юк канатым очарга» әсәрендә вакыйгалар Уфа шәһәрендә бара. Хикәя тол калган хатынның Агыйделгә карап торган бер бакчада ялгызы, хәлсезлек халәтендә йөрүен сурәтләү белән башланып китә. Язучы шушы мизгелләрдә Нәсимәнең ялгызлыктан интегүләрен, аның чарасызлык баскычындагы хис-кичерешләр дулкынын укучыга җиткерергә омтыла. Нәсимәнең сызланулы кичерешләре тасвирланган күренешләрдә экзистенциализм фәлсәфәсенең алымнары да сиземләнә. Ялгызлык халәте хис-кичерешләр сурәтләнешендә ачыла, шул ук вакытта бу кичерешләр белән бәйле вакыйгаларда Нәсимәнең үз-үзен аңлау дәрәҗәсенең үсеше дә күрсәтелә.

Әсәрдәге төп геройның исемендә үк аның эчке халәте, асыл сыйфатлары гәүдәләнә. Г. Саттар-Мулилле Нәсимә исеменең гарәп телендә «йомшак күңелле, мөлаем» мәгънәсендә кулланылуын билгели [17, 402 б.]. Аның яраткан кешесенә язучы Габдрахман исемен сайлаган, ә ул гарәпчәдән «мәрхәмәтленең, рәхимленең (Аллаһының) колы» дип тәрҗемә ителә [17, 79 б.]. М. Идрисов кыз образын мәхәббәт стихиясе аша, ә егет образын язмышка буйсыну мотивына нисбәтле шәрехли.

Хатын-кызның эчке дөньясын ачу өчен, язучы контрастлык принцибына нигезләнгән портрет алымнарын оста куллана. М. Идрисов Нәсимәнең кыз чагы белән хәзерге кыяфәтен чагыштырып тасвирлый: «Аның кыз вакытындагы озын вә тулы гәүдәсе хәзер инде нечкәргән вә юкарган; кызарып торган тулы яңаклары, шиңгән чәчәктәй, эчкә таба баткан вә агарган иде. Аның яшь вакытындагы уйнак вә сөйкемле күзләре хәзер инде сүнгән вә ялыккан, ә күз төпләре күгәргән вә эчкә таба тартылган иде» [2].

М. Идрисов героиня кичерешләрен романтикларча табигать күренешләре белән белән үреп тасвирлый. Идел елгасының язгы ташу вакытлары Нәсимә кичерешләре, ул кабул иткән чынбарлык агышы буларак күзаллана. «Аңа бу Идел, гүя үзе шикелле бәхетсезләрнең

күз яше белән ташыган төсле булып тоелды. Әнә теге тау артларында , тагы әллә кайларда – Иделнең югары тарафларында торучы әллә нинди гаиләләр эчендә санап бетермәслек киленнәр, ирдән аерылып калган хатыннар, ниһаять, көчләп кияүгә бирелгән кызларның кайнар күз яшьләре, шушы Иделдән агып баргандай булды...» [2]. Тирән хисләргә бай хатирәләр аны бер ел элек шушы бакчада ире Габрахман белән йөргән вакытларына алып китә. Алар Нәсимәнең йөрәгендә рәхәт мизгелләр булып уелып калган.

Тол хатынның газаплары кайнана һәм килен арасында булган көнләшү хисе белән тирәнәя. Нәсимә, Габдрахман әнисенең кызган чакта әйткән «угылымны сихерләп, үзеңә каратып бетергән идең» дигән авыр сүзләрен күтәрә алырлык көч тапмый. Кайнанасы алдында аның бернинди дә гаебе булмый, чөнки аларның гаилә учагы тирән мәхәббәт хисләре нигезендә туа: «Габдрахманны ул кыз вакытында әүвәл күрүдә үк яраткан вә аңа мәхәббәт баглаган иде. Габдрахманның баһадирларча киң күкрәкле таза гәүдәсе белән яңа гына сызылып чыккан кара мыегы, әүвәл танышкан дәкыйкада ук Нәсимәнең дәртле йөрәгенә кереп, рәхәт-рәхәт урнашкан иде» [2].

Кайнана тарафыннан әйтелгән нахак сүзләр, алар арасындагы низаглар Нәсимәне йорттан чыгып китәргә мәҗбүр итә. Үзанализ алымы аша, бер яктан, Мәхүпҗамалның игелексез гәмәлләренә, хаксызлыгына, икенче яктан, геройның үз халәтенә бәя бирелә: «Нәсимә ханымның җәрәхәтләнгән йөрәгенә агулы уктай булып кадалганнар иде» < > «Ник аны мин сихерлим дә, ник аны мин ата-анасыннан аерыйм? Мин аны сөйдем генә бит! Ул да мине шулай... Сөйде».

Бакчада солдатлар төркеме җырлап барган «Лимонад» татар халык җыры Нәсимә йөрәгендә тирән хисләр ташкыны тудыра. Араларында Габдрахман да бар сыман, менә-менә аның яраткан ире янына килеп чыгар күк. Экстаз хәлендә Нәсимә чынбарлык белән төштәге сыман халәт чолганышында кала.

«Менә, имеш, ул оча... Аны теге солдатлар котлыйлар. Нәсимә ханымны беравыздан:

– Бар канатың очарга! – дип олуглыйлар. Менә ул, имеш, югарыга таба күтәрелгәннән күтәрелә бара» [2].

Романтик эстетика кануннарыннан чыгып, Тургеневка ияреп, М. Идрисов музыканы кеше кичерешләре белән тәңгәллектә һәм бер дулкында геройның табигатен ачу ысулы дип саный. Шуңа күрә дә хикәядә табигать тавышлары да, халык җыры да әһәмиятле идея-эстетик вазифа башкара. Бу туй җырында гашыйкларның хисләре, аерылышу газаплары чагыла. Шул ук вакытта җырга киләчәктә яшьләрне бәхет көтә дигән фәлсәфи фикер дә салынган.

«Юк канатым очарга» һәм «бар канатың очарга» антитезасы белән язучы чынбарлык белән хыял дөньясының кисешү ноктасын бирә. Нәсимә хыялда үзенең канатлы булуын, очуын күрә. Ире аның канаты булуы да аңлашыла. Туганы Гарифнең Нәсимәне үзе белән алып китәргә килүе чынбарлыкның дәвамы булып, геройның яңа тормышка аяк басуына ишарә ясый. Габдрахман белән булган бәхетле, ләззәтле көннәр еракта калган, аңа бары хыялда гына ирешү мөмкинлеге әсәрдә канатлар символы ярдәмендә белдерелә.

Нәсимәнең яңа тормышы хакында хикәядә сөйләнелми, әмма төп геройның рухи таяныч булган туганы янында калуы аның яхшы киләчәгенә ышаныч тудыра. Автор Габдрахман белән бәйле бәхетле вакытларны тергезү алымы ярдәмендә Нәсимәнең ире белән мәңгелеккә саубуллашу мизгелләрен бәян итә.

1910 еллар татар прозасында хикәя жанры аеруча активлаша һәм аның төрле формалары иҗат ителә: психологик хикәя, публицистик хикәя, тарихи хикәя, сатирик хикәя, юмористик хикәя, хикәя-нәсер, новелла һәм башкалар. М. Идрисовның «Бәхет билеты» әсәре юмористик хикәя калыбында иҗат ителгән. Ф. Әмирхан, Ш. Камал, Г. Гобәйдуллиннарның сатирик һәм юмористик әсәрләре йогынтысында иҗат ителгән хикәядә шәһәрдә яшәүче Гайнетдин угылы Фәсхетдин һәм аның белән булган вакыйгалар сурәтләнә.

Әсәрнең сюжеты буенча Казанның элекке данлыклы Швейцария бакчасында лоторея уйнатылуы турында хәбәр тарала. Лотореяга уйнатылучы әйберләр арасында «лисәпид, көмеш сәгать, граммофон, тере сыер, Околошниковның первый сорт оны, шакмаклы шикәр, утын» вәгъдә ителә.

Чатан Әхмәдинең «мачтеровое» Фәсхетдин, ягъни Әхмәди исемле байның мастеры, очрашып йөргән кызы Шәрифә белән Швецария бакчасында лоторея билеты сатып ала һәм ул аңа тере сыер ота. Бу отышка М. Идрисов тарафыннан ироник мөнәсәбәт белдерелә: «Менә бәхет! Бәхет билеты!»

Шәһәр урамнары аша сыерны җитәкләп алып кайтканда, ул Шәрифәсе белән сүзгә керә,

Фәсхетдин төрле авырлыклар белән, ниһаять, үзе яшәгән йортка кайтып җитә. Монда исә икенче зур проблема килеп туа: сыерны кая куярга? Фәсхетдиннең исә үз йорты юк. Ул байның бер бүлмәсендә тора. Күршесе Миңлебай абзыйның көлеп әйткән киңәшләре хәлне тагын да кискенләштерә. Сыер мөгрәве тавышына хуҗа чыгып, Фәсхетдинне сыеры белән йорттан куып чыгара. Күп җәяүләп йөргәч, ул «ике бистә арасындагы нефть баклары янында» җиргә утырган хәлдә йоклап китә. Шул вакыт аның сыерын урлыйлар.

Фәсхетдин бу хәл турында хәбәр итәргә полиция участогына бара, әмма сыерның аерым билгеләрен әйтә алмагач, аның мөрәҗәгатен кире кагалар. Ул әле кичә генә бай, сыерлы иде. Бүген янында Шәрифәсе дә юк, сыеры-байлыгы да, ятарга урыны да юк. Шул рәвешле бәхет билеты алдым дип уйлаган Фәсхетдин, киресенчә, бәхетсезлек билетын отып, күңелсез һәм көлкеле хәлдә кала [3].

Әсәрдә автор Фәсхетдин образын түбәндәгечә тасвирлый: «Чынлап та, Фәсхинең башы, төп асылда, шул сыер башы хәтле генә уйлый ала иде. Ул иптәш мастерлары арасында да шул томанаклыгы, дорфалыгы белән «шөһрәт казанган» иде. Аның гакылы да шул потка тулмаенча, утыз тугыз кадак кына калган иде. Тирә-як күршеләре дә аны һәрвакыт шаярталар, мыскыллыйлар, аннан һаман көләләр иде» [3].

М. Идрисовның язу стиле дә кызыклы. Язучы халык авыз иҗаты үрнәкләрен дә куллана. Мәсәлән, «потка тулмаенча, утыз тугыз кадак» кебек әйтемнәр, канатлы сүзләр, кушаматлар белән эндәшүләр һ.б. аның стиленең үзенчәлекләре булып торалар. Әсәрнең башлам өлешендә хикәяләүче укучы белән әсәрнең исеме турында сөйләшү алып бара: «Бәхеткә билет алырга мөмкинме, әллә юкмы?» Шул рәвешле язучы серлелек өстәп, укучыда әсәргә карата кызыксыну уята, аны эстетик кабул итүгә әзерли.

## Төп нәтиҗәләр

М. Идрисовның «Юк канатым очарга», «Бәхет билеты» әсәрләре реализм ысулында язылганнар. Аларда чорның кырыс чынбарлыгы тәэсирендә герой күңелендә туган кичерешләр гәүдәләнә. Әмма ике хикәянең стиле бер-берсеннән аерыла. Беренчесендә – романтик эстетика кануннары аша сурәтләнгән Нәсимәнең эчке дөньясы, хис-кичерешләре чынбарлыкка каршылык, протест белдерүгә хезмәт итә, икенчесендә комик образлар, комик хәлләр һәм ситуация ярдәмендә чынбарлык тәнкыйтьләнә. Нечкә юмор, ачы сарказм һәм кыскалык М. Идрисов сатирик әсәренең индивидуаль хосусиятләре булып тора.

Гомумән, XX гасыр башы хикәяләренең үзенчәлекләрен әдәбият галиме Д. Заһидуллина түбәндәгечә билгели: «XX гасыр башы татар хикәясенең формалашу, әдәбиятны үзгәртү юлларын эзләү һәм жанрның үз үсешендә югары бер ноктага җитү чоры буларак бәяләнергә лаеклы» [18, 3 б.]

## Йомгак

XX гасыр башы татар әдәбияты тарихка Яңарыш чоры буларак кереп калды. Г. Тукай, Ф. Әмирхан, Н. Думави, С. Сүнчәләй, С. Рәмиев, Дәрдемәнд һәм башка язучыларның иҗатлары татар әдәбиятының алтын фондын тәшкил итә. Каләм тибрәтүче М. Идрисов та үз язмышын язучылык белән бәйләгән булса, әдәбиятта әлеге күренекле язучылар янында үзенең лаеклы урынын алган булыр иде.

**Әдәбият**


1. *Рәмиев З. З.* XX йөз башы татар әдәбияты: авторлык, төп текст һәм хронология мәсьәләләре. Казан, РИЦ «Школа», 2000. 180 б.
2. *Мөхәммәт М.* Юк канатым очарга // Аң. 1916. № 21. Б. 326–328
3. *Мөхәммәт М.* Бәхет билеты // Аң. 1916. № 22. Б. 343–346; №23. Б. 362–365.
4. НМ РТ КППи 124639. Пичахчи М. История с географией, относящиеся к истории Казанского полиграфиста-самородка Мухаммеда Ибрагимовича Идрисова, Казань. 1967.
5. *Латипов С.* Күренекле полиграфисебез // Агизел. 1967. № 5. 93–95 б.
6. *Төхфатуллин З., Кушаев Г.* Ул безнең сафта // Соц. Татарстан. 1966. 5 май.
7. *Латыпов С.* Полиграфист-ученый // Сов. Башкирия. 1966. 28 августа.
8. *Рәмиев И.* Вакытлы татар матбугаты. 1905-1925. Казан: Гажур, 1926. 232 б.
9. НМРТ КППи 124639 Труды Идрисова М.И.
10. *Мәрданов Р., Һадиев И. Б* «Милләт матбагасы һәм Мөхәммәд Идриси эшчәнлеге» // Мухаммед Идрисов – мастер шрифта / Л. И. Галиев, С. В. Морозова, Н. М. Мифтахутдинова, М. Л. Ахмадуллина, И. Г. Хадиев, Р. Ф. Мардаманова. Уфа: Восточная печать, 2022. 91–93 б.
11. *Гыйлаҗев Т.* Шәһит Әхмәдиев: тормышы һәм иҗаты // Гыйлаҗев Т.Ш. Әдәби мирас: тарих һәм заман. Казан: Татар.кит нәшр., 2005. Б. 161 – 171.
12. *Гали Б. Т.* Татарская художественная литература 1914–1917 годов как исторический источник

// Учен. зап. Казан. ун-та. Сер. Гуманит. науки. 2008. №8. С. 183 – 188;

13. *Габдрафикова Л. Р., Салихов Р. Р.* Военная повседневность в татарских баитах // Филология и культура. Philology and Culture. 2012. № 4 (30). С. 305–308.

14. *Гилазов Т.Ш.* Лирический герой поэзии М. Гафури, посвященной теме войны // Филология и культура. Philology and Culture. 2015. № 3 (41). С. 208–213.

15. *Хабутдинов А.Ю.* Тема Первой Мировой войны в татарской малой прозе начала XX века // Филология и культура. Philology and Culture. 2015. № 4 (42). С. 255–259.

16. *Гафури М.* Солдат хатыны Хәмидә // Гафури М. Әсәрләр: дүрт томда: 3 т.: Проза һәм публицистика (1902–1917). Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. Б. 267 - 295

17. *Саттар-Мулилле Г.* Татар исәмнәре ни сөйли? Казан: Раннур, 1998. 486 б.

18. Заһидуллина Д. Татар хикәяләре: XX гасыр башы. Казан: Мәгариф, 2001. 399 б.

# ИДЕЙНО-ЭСТЕТИЧЕСКАЯ И ЖАНРОВАЯ СПЕЦИФИКА РАССКАЗОВ МУХАММЕДА ИДРИСОВА

**Нурия Мидхатовна Мифтахутдинова,**
Национальный музей Республики Татарстан,
Россия, 420011, г. Казань, ул. Кремлевская, д. 2,
nurija08@yandex.ru.

В статье исследуется литературная деятельность выдающегося полиграфиста, мастера шрифтов, автора учебников М. Идрисова. Материалом для изучения послужили рассказы обладающего разносторонними талантами деятеля культуры: «Нет крыльев полететь», «Счастливый билет» были опубликованы в 1916 году в журнале «Аң» («Сознание») и стали объектом оценки научного труда. Предметом исследования является их идейно-эстетическое своеобразие.

В рассказах выявлены характерные для литературы начала XX века особенности художественного мышления, межкультурные связи, роль музыкальных образов, параллелизма явлений природы с человеческим миром в передаче эмоций героев. В рассказе «Счастливый билет» М. Идрисов пробует перо на ниве юмора и сатиры.

**Ключевые слова:** татарская литература, Мухаммед Идрисов, рассказ, жанр, литературные взаимосвязи, общественная мысль, культура